| МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ЗЕМЕЛЬНО-ИМУЩЕСТВЕННАЯ ПАЛАТА ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҖИР-МИЛЕК ПАЛАТАСЫ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ** | | **БОЕРЫК** |
| 18.05.2020 | Алабуга ш. | № 02-289 |

Алабуга муниципаль районының муниципаль казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән азат итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22 апрелендәге 821-р номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 маендагы 910-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә:

1. Алабуга муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча исәпкә алу һәм мөлкәт идарәсе бүлегенә һәм җир мөнәсәбәтләре бүлегенә:
   а) арендаторлар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы, яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә ситуациянең начараюы шартларында аеруча зыян күрүче (аларның исемлеге «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә ситуациянең начараю шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән 7 эш көне дәвамында 2020 елның апрель-июнь айлары өчен аренда түләүләрен түләүдән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге тәэмин итәргә. Күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү Алабуга муниципаль районының муниципаль казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль милекне арендага бирү каралган очракта, әлеге төр

эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен һәм күрсәтелгән төр эшчәнлекне (төрләрен) башкару өчен аннан файдалану максатында муниципаль мөлкәтне арендага бирү каралган һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (эшчәнлек төрләрен) башкару өчен тиешле мөлкәтне куллануны раслаучы документлар булган очракта, күрсәтелгән аренда түләүләреннән азат итү гамәлгә ашырыла;

б) әлеге күрсәтмә үз көченә кергән көннән өч эш көне эчендә, Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итәргә.

2. Әлеге каракүрсәмәдә каралган, аренда түләүләреннән азат итү Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү датасына әлеге күрсәтмәнең 1 пункты «а» пунктчасында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган Алабуга муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чор өчен аренда түләүләре буенча үтәлмәгән бурычы булмаган арендачыларга карата гамәлгә ашырыла дип, билгеләргә.

3. Әлеге күрсәтмә рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.С. Гыйззәтуллин